РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» ноябрь 2021 ел г. Альметьевск № 1668

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп килергә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидияләр бүлеп бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 13 ноябрендәге 1661 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп килергә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидияләр бүлеп бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 13 ноябрендәге 1661 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

2 бүлек таблицасындагы 2.5 юлындагы 11 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;»;

2 бүлек таблицасындагы 2.6 юлын түбәндәге эчтәлекле яңа 5 пунктча өстәргә:

«5) гражданлык хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрында булган тууны дәүләт теркәве, никахны йомгаклау һәм өзү турында белешмәләр, һәм туу турында актлар язмасына төзәтмәләр яисә үзгәрешләр кертү турында, никах төзү һәм өзү турында гражданлык хәле актлары язмаларының бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр.»;

3 бүлекнең 3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа 3.4.1.5 пунктчасы өстәргә:

Зак. № 305-2000

«3.4.1.5. Гражданлык хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрында булган тууны дәүләт теркәве, никахны йомгаклау һәм өзү турында белешмәләр, һәм туу турында актлар язмасына төзәтмәләр яисә үзгәрешләр кертү турында, никах төзү һәм өзү турында гражданлык хәле актлары язмаларының бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр.».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ